# ГАЛӘМ

*Ноябрь*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

***№3***




4 НЧЕ НОЯБРЬ -ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ.УЛ ТЫНЫЧЛЫК, ИМИНЛЕК ,БӘЙСЕЗЛЕК, БЕРДӘМЛЕК СИМВОЛЫН ЧАГЫЛДЫРА. ДӘҮЛӘТ КҮЛӘМЕНДӘГЕ БУ БӘЙРӘМ 1612 НЧЕ ЕЛГЫ ТАРИХИ ВАКЫЙГАЛАРГА БАРЫП ТОТАША. ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ БУЛАРАК, 2005 НЧЕ ЕЛДАН БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ.




ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕН КАБУЛ ИТҮ КӨНЕ 1992 ЕЛДАН БАШЛАП БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ. БУ БӘЙРӘМ РЕСПУБЛИКА ТӨП ЗАКОНЫНЫҢ АЕРЫМ ӘҺӘМИЯТЕН, ДӘҮЛӘТНЕҢ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ ЗАКОНЛЫЛЫКНЫ ҺӘМ ХОКУК ТӘРТИБЕН НЫГЫТУГА ОМТЫЛЫШЫН ГӘҮДӘЛӘНДЕРӘ.



БЕЗ СПОРТНЫ ЯРАТАБЫЗ

КАНИКУЛ ЧОРЫНДА ДА УКУЧЫЛАР ТҮГӘРӘКЛӘРГӘ ЙӨРҮЛӘРЕН ДӘВАМ ИТТЕЛӘР.АЕРУЧА ТЕННИС, БАДМИНТОН, КӨРӘШ ТҮГӘРӘКЛӘРЕН КӨТЕП АЛАЛАР АЛАР “СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ – СӘЛАМӘТ АКЫЛ” ДИП ЮККА ГЫНА ӘЙТМИЛӘР БИТ. СПОРТТА ДА, УКУДА ДА СЫНАТМЫЙЛАР БЕЗНЕҢ УКУЧЫЛАР.




МӘКТӘБЕБЕЗДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ЯЛЫН ФАЙДАЛЫ ИТЕП УЗДЫРУ ӨЧЕН КУП ЭШЛӘР БАШКАРЫЛА. ТЗНЗФЕСТӘ ДӘ ТЕННИС ӨСТӘЛЕ ТИРӘСЕ ГӨРЛӘП ТОРА. ТИК УКУЧЫЛАР ТАРАЛГАЧ АНДАГЫ ТӘРТИПНЕҢ САКЛАНМАВЫ ГЫНА КУҢЕЛЛЕ КУРЕНЕШ ТҮГЕЛ. МӘСӘЛӘН, 5 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ФОРМАЛАРЫ БЕРНИЧӘ КӨН ҮЗ ХУҖАЛАРЫН КӨТТЕ.



**Укучыларыбыз сынатмаслар дип уйлыйбыз.**
Атна башыннан муниципаль олимпиадалар башланып китте.Укучыларга уңышлар телибез. Җиңел аяктан.
(Мустафина Айсылу, Салахиева Мәдинәләр беренче олимпиадага киттеләр.Уңышлар аларга)

**Бәйрәмнәр дәвам итә**

18 ноябрь конне мәктәбебездә башлангыч сыйныфларда “Көзне озату” бәйрәме булып үтте.Бәйрәм зур әзерлек белән оештырылган иде.Укучылар рәхәтләнеп күңел ачтылар һәм бик кәнәгать калдылар.





**Наркомания -афәт ул.**

Наркотикларга каршы чаралар айлыгы бара.Шул уңайдан 17 ноябрь көнне мәктәбебездә “Наркомания -афәт ул” дип исемләнгән сыйныф сәгате үтте.Әлеге чара 5- 9 сыйныф өчен үткәрелде.Укучылар үзләре чыгыш ясадылар һәм нәтиҗәләр дә чыгардылар.


**ТӨРЛЕЛӘР**

-Үткән атнада 4,6,8 сыйныфлар офлайн режимда инглиз теленнән тестирование үттеләр.
-18 ноябрь көнне әти-әниләр җыелышы булып узды.
-ЮИД дәресләре үткәрелде

.-Мәктәбебездә Әниләр көненә әзерлек башланды.







-Дәресләр бетте. Хуҗам кайтып китте.Ә мин тагын биредә калдым.

Бу хәл бер генә сыйныфта күзәтелмәде.(Узган атнада гына бу турыда сөйләшкән идек тә бит)

**Чираттагы сәфәр**


20 ноябрь көнне Балык Бистәсе агротехник техникумында "Все краски мира" дип исемләнгән зональ форум булып узды. Форумда мәктәбебез укучылары Сәләхиева Мәдинә һәм Фарзутдинова Гүзәл катнаштылар.




***#стопвичспид***

30 нчы ноябрь көнне 7-9 сыйныф укучылары **#стопвичспид** акциясендә катнаштылар. Бу акция бөтен Россия күләмендә **СПИД**ка каршы көрәш көне уңаеннан үткәрелде.





**Олимпиадалар**

13 ноябрьдән Бөтенроссия фән олимпиадаларының муниципаль этаплары башланды.Төрле фәннәр буенча олимпиадаларда мәктәбебез данын Кәримуллина Гөлзидә, Низамов Фәнзил, Гилемханова Энже, Сәләхиева Мәдинә, Мостафина Айсылу, Фарзутдинова Гүзәл , Вафин Рүзәл һәм Сергеев Камил якладылар. Алардан яхшы нәтиҗәләр көтеп калабыз . Киләсе олимпиадаларда да уңышлар телибез .

**Авырмас өчен файдалы киңәшләр:** Саф һавада күбрәк йөрсәң әйбәт. Тиешенчә йокларга, аксымга, витаминнарга һәм минераль матдәләргә бай ризык белән тукланырга, физик яктан актив булырга кирәк. Кулларны сабын белән еш юарга, кеше күп йөри торган урыннарга бармаска, бүлмәләрне җилләтеп торырга, әңгәмәдәшеңә якын килеп сөйләшмәскә киңәш ителә.





# *Әниләр көне!*

28 ноябрь көнне мәктәбебездә “Әниләр көне” нә багышланган чара булып узды. Бәйрәмгә чакырылган әниләребезнең барысы да килгән иде. Чарада укучыларның гына түгел, әниләрнең дә уеннарда катнашуы бәйрәмне тагын да җанлырак итте.Әниләребезгә карата хөрмәт тәрбияли торган бу бәйрәм барыбызга да ошады.

29 нчы ноябрь көнне 9нчы сыйныф укучылары Кәримуллина Гөлзидә,Гыйлемҗанова Адилә,8нче сыйныф укучысы Сәлахиева Мәдинә Зур Мәшләк авылында узган "Әхмәт Гадел укулары"дип аталган конференциядә уңышлы чыгыш ясадылар.Аларга алга таба да уңышлар телибез!!!



Шулай ук бу атнада авылыбызда төшерелгән беренче кыска метражлы нәфис фильмны тәкъдим иттеләр. Әлеге фильмда безнең мәктәп хезмәткәрләре дә катнашты. Фильм барыбызда да якты хатирәләр калдырды. Мәктәбебез тарихында әлеге чара үз урынын алыр.